СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО
ОБРАЗОВАНИЯ
«ЛЕНИНОГОРСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
«ЛЕНИНОГОРСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ
БЕРӘМЛЕГЕ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2019 елның 6 июне Лениногорск №27

Лениногорск муниципаль районы Советының 2017 елның 15 мартындагы 30 номерлы карары белән расланган Лениногорск муниципаль районында муниципаль хезмәткәрләр реестрын алып бару тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Лениногорск муниципаль районы Советының 2017 елның 15 мартындагы «Лениногорск муниципаль районында муниципаль хезмәткәрләр реестрын алып бару тәртибен раслау турында» 30 номерлы карары белән расланган Лениногорск муниципаль районында муниципаль хезмәткәрләр реестрын алып бару тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) 7 пунктның 3 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Муниципаль хезмәттән азат ителгән муниципаль хезмәткәр эштән азат ителгән көнне муниципаль хезмәткәрләр реестрыннан төшереп калдырыла.

б) түбәндәге редакөиядәге 4нче абзац белән тулыландырырга:

Муниципаль хезмәткәр вафат булган (һәлак булган) очракта йә муниципаль хезмәткәрне законлы көченә кергән суд карары белән вафат булган дип таныган яисә игълан иткән очракта, муниципаль хезмәткәрләр реестрыннан үлем (һәлак булган) көне яки суд карарының законлы көченә керү көне артыннан килгән көнне төшереп калдырыла.

2. Әлеге карарны Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (leninogorsk.tatar.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге аппараты җитәкчесе Н.Г.Шәйхетдиновка йөкләргә.

Лениногорск муниципаль район
Башлыгы, муниципаль район Советы Рәисе Р.Г.Хөсәенов